# КАРАР

**2022 елның 23 ноябре** **№ 2**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 23 ноябрендә 10.00 сәгатьтә һәм 2022 елның 23 ноябрендә 14.00 сәгатьтә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, түбәндә санап кителгәннәрдән кала:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 яки аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары» – һәр балигъ булган кешедән 900 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә ризамы:

- су башнясы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Байлангар авылы клубына җиһазлар һәм спорт инвентарьлары сатып алу;
- янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Байлангар авылы территориясен төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Совет урамы тыкрыгын төзү һәм ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү)
- ял итү зоналарын булдыру һәм төзекләндерү буенча чараларны гамәлгә ашыру һәм ял итү зоналарын төзекләндерү; Сабантуй бәйрәмен уздыру урыны территориясен төзү һәм төзекләндерү; ( сәхнә, тамашачылар өчен эскәмияләр, спорт инвентарен саклау өчен бина төзү, проект-смета документларын эшләү; материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- зиратны карап тоту; бәдрәф һәм инвентарь сатып алу (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);
- Су башняларын ремонтлау һәм буяу, Байлангар авылы артезиан коесы өчен насос сатып алу (проект-смета документларын эшләү килешү буенча түләү);
- Урамнарны яктыртуны карап тоту; (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, проект-смета документларын эшләү , килешү буенча түләү);
- Байлангар авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорларда карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запчастьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә: Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 521 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **270**.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 265 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «2023 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, түбәндә санап кителгәннәрдән кала:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
-18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 яки аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокլы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары» – һәр балигъ булган кешедән 950 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә ризамы:

- су башнясы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Байлангар авылы клубына җиһазлар һәм спорт инвентарьлары сатып алу;

- янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Байлангар авылы территориясен төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Совет урамы тыкрыгын төзү һәм ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү)

- ял итү зоналарын булдыру һәм төзекләндерү буенча чараларны гамәлгә ашыру һәм ял итү зоналарын төзекләндерү; Сабантуй бәйрәмен уздыру урыны территориясен төзү һәм төзекләндерү; ( сәхнә, тамашачылар өчен эскәмияләр, спорт инвентарен саклау өчен бина төзү, проект-смета документларын эшләү; материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- зиратны карап тоту һәм төзекләндерү (бәдрәф һәм кораллар, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

- Сууткәргеч челтәрен һәм су башняларын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү (су башняларын буяу, Байлангар авылы артезиан скважинасы өчен насос сатып алу, материаллар сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

- Урамнарны яктыртуны карап тоту; (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, проект-смета документларын эшләү , килешү буенча түләү);

- Байлангар авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорларда карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запчастьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Байлангар авылында Ф. Заһидуллин урамы буенча 5 нче урам яктырту линиясен үткәрү, материал сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);
- Байлангар авылы урамнарына вак таш сатып алу һәм җәю (килешү буенча түләү)
- Байлангар авылында автомобиль күперен төзү һәм ремонтлау (проект-смета документациясен эшләү, технадзорны тормышка ашыру)?

«РИЗА» «КАРШЫ» - кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Байлар авыл җирлеге башлыгы И. Ф. Кәримуллин